| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>Салаушского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Салагыш авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.02.2022 Салагыш авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районының «Салагыш
авыл җирлеге» муниципаль
берәмлегенең Яморза торак пунктында
гражданнар җыенының нәтиҗәләрен
бетерү мәсьәләсе буенча җыенын
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башлыгы к а р а р  и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яморза авылындагы гражданнар җыенын 2022 елның 23 февралендә нәтиҗәләре турында карарын юкка чыгару мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Яморза торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын 2022 елга кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яморза авылындагы гражданнар җыенының нәтиҗәләрен 2022 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану

мәсьәләсе буенча сайлау хокукына ия булган кирәкле сандагы халык булмау сәбәпле аларның салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гамәлдән чыгарырга килешәсезме? “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы нигезендә әлеге статьяда каралган гражданнар җыены анда торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия (йә аның территориясенең бер өлеше) яисә җирлектә яшәүчеләрнең яртысыннан күбрәге катнашканда хокуклы.

« риза » «каршы»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Яморза ав., Елга ур., авыл мәдәният йорты территориясе.
4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга.
6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы М.М.МӨХӘММӘДИЕВ